РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.05.2020

КАРАР
№ 21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеген раслау

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы 06.04.2020 ел, №18 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 2 нче пункты нигезендә, Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев

Расланган
Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 28.05.2020 ел, № 21 карары белән

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеге**

| Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль | Өч һәм аннан да күбрәк баласы | Өч һәм аннан күбрәк баласы | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2018 елның 1 гыйнварынн | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| районы Юлбат авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 25 нче мартында кабул ителгән 10 нчы номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 32 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында» | булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балаларны физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү | булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балалар | | ан башлап | | | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы | Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын җир | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тарафыннан 2019 нчы елның 26 нчы ноябрендә кабул ителгән 28 нчы номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Юлбат авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» | салымыннан азат итү | | | | | | | |